КЕРЕШ

Синонимнар — мәгънәдәш сүзләр, һәм алар фикерне төгәл, анык, җыйнак итеп формалаштырырга мөмкинлек бирәләр, сөйләмне матур яңгырашлы, аһәңле ясыйлар, күренеш һәм төшенчәләрне, аларның билгеләрен төрле-төрле мәгънә төсмерләре һәм стилистик бизәкләр белән аңлатып, тасвирлап бирергә ярдәм итәләр.

Татар теле — синонимнарга бай тел. Бу, мөгаен, телебезнең борынгыдан ук яшәп, чарланып килүеннән, халкыбызның мәгълүматлы, укымышлы тарихи халык булуыннан, үз теленә яратып, игътибар һәм ихтирам белән каравыннандыр. Дөрес, соңгы чорда телебезнең шактый зур байлыгы рус һәм интернациональ сүзләр тарафыннан кысрыкланып, рус телендә генә сөйләшергә тырышкан яшь буын өчен бик сыегайды, газета-журнал һәм дәреслек битләрендә русчадан тәрҗемә ителгән, инде шомарган, шаблонлашкан сүзләр генә урын ала, ә телебезнең иң нәфис, фикерне төгәл бирә торган сүз һәм сүз тезмәләре яшәештән төшеп кала башлаган иде. Халкыбыз, телебез тарихында булган менә шушы ялгышны төзәтү, җитешсезлекне киметү максатында синонимнар сүзлеге үзеннән өлеш кертер дигән өметтә калабыз.

Ш.С.Ханбикованың 1962 елда чыккан “Синонимнар сүзлеге”н исәпкә алмаганда, татар теле синонимнарын барлап, туплап биргән хезмәтләр күренми. Дөрес, кайбер мәкаләләрдә синонимик оялар исемлеген очратабыз. Биредә аларга анализ ясап тормастан, чыккан “Синонимнар сүзлеге”-нең кечкенә булуын, 2000 сүзне берләштергән 400 оядан гына гыйбарәт икәнен истә тотып, зуррак сүзлек төзеп бирергә булдык. Бу сүзлек **25 меңгә** якын синонимик берәмлекне берләштергән **4500дән** артык оядан тора. Ләкин теге сүзлекнең өстенлеге — һәр ояга аңлатмасы һәм һәр сүзнең телдәге кулланылышын күрсәткән мисал булуда. Бу сүзлек тә матур әдәбият әсәрләреннән, халык авыз иҗатыннан, дәреслекләрдән, сүзлекләрдән чыганагы күрсәтелеп эшләнгән картотека нигезендә төзелде. Шулай да, мондый сүзлекләргә халыкның ихтыяҗын искә алып, башта синонимик оялар исемлеге рәвешендәге сүзлекне төзеп чыгара торырга уйладык. Ходай кушкан булса, киләчәктә аңлатмалы һәм тагы да тулырак синонимнар сүзлеген бирербез дигән нияттә калабыз.

Сүзлекне төзегәндә, синонимнар — мәгънәдәш сүз (һәм сүзтезмәләр) дигән караштан чыгып эш иттек. Мәгънәдәшлек төшенчәсен ничек аңлыйбыз соң, синоним төшенчәсенә нинди аңлатма бирәбез, һәм телдә синонимнар ничек барлыкка киләләр?

Синонимнар телдә бер төшенчә аңлатып, сөйләмдә бер функцияне үти торган сүз һәм сүзтезмәләр. Ләкин болар телдәге вариантлар, параллельләр түгел, мәгънәләре уртак булган хәлдә, бер-берсеннән теге яки бу күләмдә аерым билгеләр, төсмерләр белән аерылалар. Алар арасындагы аерымлык мәгънә төсмерендә яки куллануш функциясендә булырга мөмкин. Мәсәлән, *куныч, балтыр* синонимик оясындагы сүзләр *итек, оек* кебек сүзләр янында яки шулар турында сүз барган контекстта бер үк мәгънә аңлатып, берсе урынына икенчесе килә ала: *итек балтыры, оек балтыры, кыска яки озын балтырлы* һ.б. телдә еш кулланыла, әдәби әсәрләрдә күп кенә язучыда очрый, ләкин төп мәгънәне *куныч* сүзе ачыграк бирә, аның мәгънәсе, кайсы контекстта яки нинди сүз янында килүенә карамастан, конкретрак һәм бер генә. Шуңа күрә ул синонимик ояда баш сүз — **доминанта** итеп китерелә. *Балтыр* сүзенең төп мәгънәсе аякның бер өлеше — тубыктан тезгә кадәрге аяк төшенчәсен аңлата һәм телдә *сыйрак, чәркә, чәлтер* сүзләре белән синоним кулланыла, термин буларак та, әдәби телдә дә йөри. *Сыйрак, чәркә, чәлтер* сүзләренең өстәмә мәгънә төсмерләре, *балтыр*дан аермалары күзгә ташлана: *сыйрак* — озын, нечкә, сөякчел балтырны, гомумән колгасар ябык кеше аягын аңлатса, *чәркә, чәлтер* сүзләрендә бу төсмер тагы да көчлерәк бирелә, мыскыллы көлү карашы өстәлә. Бу ояда баш сүз — *балтыр.* Тагын бер мисал: *калын* һәм *юан* сүзләре нинди әйбернең билгесе булып кулланулары ягыннан аерылалар кебек, ягъни болардагы төсмер төп мәгънәгә якынрак тора, шунлыктан кайбер сүзләр янында синоним була да алмыйлар: *калын такта* юан була алмаган кебек, *юан инә* калын була алмый шикелле. Шулай да, *“калын бармаклы куллар”* ... (К.Нәҗми), ... *“юан буынлы бармаклары белән”* ... (Г.Бәширов) кебек танылган язучыларыбыздан китергән мисалларда боларның синонимлыгы табигый яңгырый, кешеләр дә бит, артык тазарсалар калынаялар, юанаялар, калын гәүдәле яки юан гәүдәлегә әвереләләр. Димәк, бу сүзләр арасындагы синонимлык та табигый, бары тик мәгънә төсмерләрен аңлап, урынлы куллана белергә кирәк икән.

Синонимлыкны барлыкка китерә һәм алар арасындагы аерымлыкны бирә торган төсмерләр — мәгънә төсмере нәрсә соң ул? Аның нинди төрләре бар?

Мәгънә төсмере — сүзнең семантик үзенчәлеге, мәгънәне, төшенчәне барлыкка китерүче билгеләр бердәмлеге ул. Сүзнең мәгънәсендә төп һәм өстәмә билгеләр була. Сүз мәгънәсендәге өстәмә билгеләр — синоним сүзләрне бер-берсеннән аера торган мәгънә төсмерләре алар. Болардан тыш, сүзнең мәгънәсенә карамый, бәлки сөйләмдә теге яки бу стилистик максатка хезмәт итүенә, функциясенә генә карый торган төсмерләр дә була. Мәсәлән, *кадау—чәнчү*, яки *бату—чуму—күмелү* ояларындагы өстәмә төсмерләр сүзләрнең мәгънәсендә үк булса (*чәнчү*дә кечкенә әйбер белән кадау, *чуму*да тирәнгә, төпкә китү, *күмелү*дә тулысынча бату), *сәләт—талант* яки *кычкыру—акыру* ояларында *талант*ның зур сәләт, *акыру*ның нык, каты итеп кычкыру градацияне бирүдә күренә; ә *чират—нәүбәт* яки *чиләк—бидрә, семья—гаилә* кебек синонимнарда мәгънә ягыннан аерымлык сизелми, болар телдә актив яки пассив кулланышта булалар, стилистик төсмерләр белән генә аерылалар, күп очракта, контекстка карап, бер-берсен алмаштырып килә алалар.

Тагын бер мисал: *йорт, өй, бина, ызба* сүзләре синонимлыгын карыйк: кешеләр, урман кисеп, бүрәнәләрдән бура бураганнар һәм өй күтәргәннәр, шул өйнең түбәсен ябып, яшәрлек хәлгә китергәннәр; *өй түбәсе, өй дивары, өй идәне, өй сылау, өй юу (өмәсе), өй котлау (мәҗлесе), өй ашы, өй чикерткәсе* ... кебек сүзтезмәләр барлыкка килгән. *Өй* сүзенең *йорт* дигән мәгънәдәше дә бар. Ләкин алдагы тезмәләрдә *йорт* сүзен *өй* сүзе урынына кулланып булмый. Дөрес, *йорт түбәсе* дигән тезмә телдә йөри. Бу кайбер авыллардагыча барлык төзелешне, кураны түбә астында калдыруны күздә тота. *Йортка чыгу — башка өйгә күчү, башка чыгу, үзенә аерым йорт төзү, аерым йорт белән яшәү, йортка керү* һ.б. тезмәләрдә *йорт* сүзе *өй* төшенчәсенә *хуҗалык* төшенчәсен дә өсти; *авылда ничә йорт бар, йорт башыннан түләү, йорт хуҗасы* һ.б. да бу мәгънә тагы да көчәя төшә. Шулай да, *йорт*ның *өй* сүзе белән уртак кулланышы да шактый: *агач яки таш өй // йорт, зур йортка // өйгә күчү, шәһәр йортлары// өйләре, берничә катлы йортта// өйдә тору, җиде катлы өйнен//йортның түбәнге катында яшәү, елга буендагы өйләрне//йортларны су баскан* һ.б. Димәк, өй һәм йорт сүзләрендәге уртаклык кешеләр яши торган бина булуга нигезләнсә, аерма йортның өйгә караганда зуррак булуы, өй тирәсе корылмаларын да үз эченә алуы, гомумән, яшәү урынын аңлату белән аерыла. Бу синонимик ояга *бина* сүзен дә кертергә мөмкин. Бу сүз дә *корылма, йорт* мәгънәсен аңлата. Ләкин татарлар бу сүзне, кешеләр яши торган өй мәгънәсеннән аермалы буларак, русның *“здание”* сүзе мәгънәсендә *корылыш, төзелеш* төсмерләре белән кулланалар: *мәктәп бинасы, көтепханә бинасы// өе, поликлиника бинасы, завод-фабрика биналары* һ.б.ш. Шәһәрнең уртасында *яңа йорт, яңа биналар* калкып чыкты дисәк, бу аерымлык тагы да калкурак чагыла. *Өй* сүзенең мәгънәви варианты буларак мишәр халкында *“ызба“* сүзе кулланыла. Ләкин моны әдәби әсәрләрдә кемнәр тормышын тасвирлауны күздә тотып кына файдаланырга мөмкин, ягъни, бер үк мәгънә аңлатсалар, да бер-берсен алмаштырып килә алмыйлар.

Синонимлыкны билгеләүдә дә сүзләрнең бер-берсен алмаштыра алулары нигез билгеләрдән санала. Ләкин телдә андый паралельләр, дублетлар, беренчедән, күп түгел, икенчедән, мондый паралельлек телдә озак яшәми; андый тәңгәл сүзләр-вариантлар вакытлар үтү белән, я берсе активлашып, икенчесе телдән төшеп кала, яки берәрсенә нинди дә булса мәгънә төсмере беркетелеп, бу сүзләр мәгънә төсмерләре аерыла торган сүзләргә әйләнә баралар. Тел һәрвакыт үсеш, үзгәреш хәлендә булып, сүзләр дә семантик үсеш, үзгәреш кичерәләр. Шунлыктан, бу сүзләр тәңгәлләр, боларның мәгънәләре белән аерылалар дип бүлү билгеле бер чор өчен генә дөрес була. Телнең шундый үзгәреш хәлендә булуы, шулай ук сүздәге мәгънә төсмерләренең күп һәм төрле булуы синонимик ояларга җыйнау һәм оя чикләрен билгеләү эшен дә кыенлаштыра.

Тел — билгеле бер эпоха продукты гына түгел, ул җәмгыять белән туып, үсә, һәрвакыт үсеш, үзгәреш хәлендә тора; тел — күп эпохалар продукты. Җәмгыятьтә булган үзгәрешләр яңа төшенчәләрнең тууы, халыкларның аралашуы, кушылуы нәтиҗәсендә бер үк халыкта бер төшенчәдә йөри торган параллель сүзләр барлыкка килә, ләкин болар параллель рәвештә озак йөрмиләр, вакытлар үтү белән, бердән артыгы кулланыштан төшеп кала, югала яки башка мәгънә төсмерләре белән файдаланыла башлый, телдә синонимнар барлыкка килә.

Телдә синонимнар барлыкка килүнең төп ике юлын күрсәтергә кирәк:

1) бер төшенчәдә йөргән сүзләрнең төрле кабилә һәм халыклар теленнән керүе;

2) телнең үз байлыгы нигезендә синонимнар ясалу.

Ләкин бу ике юлны бер-берсеннән аерып карау дөрес булмас, алар бер-берсенә тәэсир иткәннәр, бер үк тарихи процесста үрелеп барганнар.

Башка теллəрдəн сүзлəр керү үзе берничə төрле юл белəн барган:

а) кабилəлəр кушылу процессында кушылучы теллəрдəге сүзлəр һəм сүзтезмəлəр гомумхалык теленə кергəннəр һəм параллель яки синоним сүзлəр булып киткəннəр;

б) халыклар аралашу нигезендə башка халыклар теленнəн сүз һəм сүзтезмəлəр алынган, телнең үз сүзе белəн паралель йөри башлаган.

Моңа мисалны ерак тарихка китмичə, соңгы гасырда рус теленнəн яки рус теле аша башка теллəрдəн кергəн сүзлəр, сүз-терминнарны күзəтү яки тугандаш халыклардан кергəн сүзлəрне искə алу юлы белəн дə күрсəтергə була.

Берничə мисал: əдəби телдə соңгы елларда активлашып киткəн башкортның *тəүге* сүзе *беренче тапкыр* мəгънəсендə бик матур һəм уңышлы яңгырый, ул *беренче* сан-терминның синонимы түгел; *беренче мəхəббəт, беренче көрешү* сүзтезмəлəренə синоним кулланылган *тəүге мəхəббəт, тəүге көрешү* формасында тагы да төгəлрəк, сəнгатьлерəк яңгырый. Башкорт телендə һəм Татарстанның күп кенə районнарында кулланыла торган *муел* сүзе дə хəзер инде татар матур əдəбиятында, шигырьлəрендə, хəтта татар халык җырларында шактый еш күренə, ул *шомырт* сүзенə параллель кулланышка кереп бара. Лəкин хəзергə татарлар муел агачын һəм муел чəчəген мактасалар да, муелны түгел, шомырт кыла ашыйлар кебек. Димəк, бер тел параллельлекне өнəми, аннан качарга тырыша, хəтта читтəн алынган сүзне дə үзенчə формалаштыра, аның мəгънəсен я кыса, я киңəйтə, өстəмə төсмерлəр белəн баета. Сүзлəрнең мəгънəлəре үзгəрү, мəгънə төсмерлəре өстəлү алынма сүзлəргə генə карамый, алынма сүзлəр тəэсирендə тел элек яшəп килгəн сүзнең дə мəгънəсен үзгəртергə — киңəйтергə яки тарайтырга, функциясен кысарга мөмкин. Мəсəлəн, соңгы елларда кергəн *закон* сүзе телнең күп еллардан бирле кулланылган *канун* сүзен шактый тарайта башлаган иде. Шулай булуга карамастан *канун* сүзе өстəмə төсмер дə алды кебек: *кагылгысызлык, катгыйлык* законга караганда да көчлерəк.

Димəк, синонимнар барлыкка килүнең анда бəян ителгəн ике юлы бер-берсе белəн аерылгысыз, бергə үрелеп бара, берсе икенчесен барлыкка китерə.

Синонимнарның телнең үз байлыгы нигезендə ясалуы үзе берничə юл белəн барган:

а) сүзлəрнең мəгънəлəре үзгəрү, мəгънə төсмерлəре өстəлү яки кайбер билгелəрен югалту — **семантик юл;**

б) сүз яки грамматик формаларда авазлар үзгəрү — **фонетик юл** (*себерү—сыпыру, кучү—кичү, тугры—туры—турылыклы*);

в) төп сүзгə синоним сүз яки бер үк функцияле кушымчалар ялгану юлы белəн — **морфологик юл** (*ут-күз, бала-чага, булдыклы-булган, эшлекле-эшчəн, динле-динчел-диндар, хөрмəт итү-хөрмəт əйлəү-хөрмəтлəү, баш-башлык-башчы* һ.б.).

Болардан тыш тагын сүзлəрне күчмə мəгънəдə кулланып, шул күчмəлекнең сүз мəгънəсенə əйлəнеп китүе һəм тел берəмлегенə əйлəнүен дə күрсəтеп үтəргə кирəк. Телебездəге синонимлыкка бер төшенчə аңлата торган сүзтезмəлəр дə зур гына өлеш кертə. Мəсəлəн, *баш тарту—баш каеру—ваз кичү—кире кагу—кире кайту* кебек бер төшенчə аңлата торган синонимнар оясына телебездə сирəгрəк кулланыштагы *түнү—дүнү—айну* сүзлəрен генə өстəргə була, иң активлары сүзтезмəлəрдəн тора.

Димəк, синонимика — тарихи күренеш. Ул тел үсешенең барлык чоры өчен дə абсолют үзгəрешсез категория түгел. Бер чорда синоним итеп кулланылган сүзлəр, вакытлар үтү белəн, синонимлыкларын югалта, шулай ук синоним парлары булмаганнары синонимлашырга, яңа синоним парлар барлыкка килергə мөмкин. Синонимнар телнең иҗатчысы— халык тарафыннан тудырылалар. Төгəл, анык уй йөртүе, чынбарлыкны аңлавы, табигать серлəренə төшенүе, иҗади һəм культура дəрəҗəсе үскəн саен, халык телен дə синоним сүзлəргə, сүзтезмəлəргə һəм грамматик формаларга баета, камиллəштерə, һəр сүзенə тарихи нигезлəнгəн анык, конкрет мəгънəне беркетə бара. Бу исə телнең үсешенə, сүзлек составының баюына китерə. Сүзлек составының баюы телнең үсеш тенденциясенə нигезлəнə. Телнең үсеш тенденциясе, беренчедəн, конкретлыкка, төшенчəне анык һəм төгəл бирүгə омтылу булса, икенчедəн — кыскалыкка омтылу, кабатлаулардан, артык сүз һəм формалардан котылырга тырышу. Шул нигездə яңа синонимнар барлыкка килə, тел дə байый, камиллеккə, төгəллеккə ирешə.

СИНОНИМНАР СҮЗЛЕГЕ

Синонимнар сүзлегенең ике төрен күрсəтеп үтəргə кирəк:

а) аңлатмалы синонимнар сүзлеге;

б) синонимик оялар һəм синоним сүзлəр исемлеге.

1962 елда Ш.С.Ханбикова тарафыннан төзелеп нәшер ителгән “Синонимнар сүзлеге“ беренче төргә карый. Анда доминанта сүз янына аның синонимнары тупланып, ояга һәм оядагы һәр сүзгә аңлатма бирелә һәм әдәби әсәрләрдән һәр сүзгә мисал китерелә. Сүзлек азагында синонимик оялар индексы һәм синоним сүзләрнең алфавитлы индексы өстәлә. Сүзлектән бер мисал:

Бурыч, әҗәт, көтәчәк, бирәчәк, үтеч.

Билгеле бер вакыт үтү белән хуҗасына кайтарылырга тиешле нәрсә мәгънәсен бирәләр. **Бурыч** — киңрәк мәгънәдә — үтәлергә тиеш булган эш мәгънәсендә дә йөри. **Әҗәт, үтеч** — күтәргә алган акча яки әйбер. **Көтәчәк** (көтәчәккә алу) — бераздан кайтару шарты белән алынган нәрсә. **Бирәчәк** шул ук бурыч мәгънәсендә йөри.

Таңнан талаганнар карт кешене,
Мескен ***бурыч*** *хәле нинди кыен ул.*
(Ф.Кәрим)

— ... Әгәр без җитмәгән орлыкны үз арабыздан җыеп алсак. Ә?! ***Әҗәткә*** *биреп торсак көзгә хәтле? (Г.Бәширов).*

Срогы җиткәч **бирәчәк**не түләргә кирәк. (Ш.Мөхәммәдиев)

Орлыгың аз булса, үзем
Көтәчәккә бирермен.
(М.Җәлил)

Үтечкә алган атка менгән тиз төшәр. (Мәкаль).

Мондый тип синонимнар сүзлеге башкортларда 1966 елда З.Г.Ураксин тарафыннан эшләнде (З.Г.Урасин. Башорт теленең синонимдәр һүззеге. Өфө, 1966, 270 бит — 2000 гә якын сүзне берләштергән 480 оя), русларда исә 1783 елда Д.И.Фонвизинның 32 синонимик ояны китергән “Опыт российского сословника”, 1818 елда П.Калайдовичның 77 синонимик ояга характеристика биргән “Опыт словаря русских синонимов” хезмәтләреннән башлана. 1956 елда В.Н.Клюева чыгарган “Краткий словарь синонимов русского языка” (1482 сүзне берләштергән 314 оя; 1961 елда тулыландырылган икенче басмасы ике тапкырга диярлек арта), 1970—1971 елларда А.П.Евгеньева редакциясендә зур коллектив төзеп чыгарган ике томлык сүзлек (Словарь синонимов русского языка. I том, 1970, 680 стр. — 1958 синонимический ряд; II том 1971, 856 стр. — 2180 синонимический ряд) аңлатмалы сүзлек тибына карый.

Синонимнар сүзлегенең бу төре ике максатны — ике төрле эшне башкаруны таләп итә: беренчедән, синонимнар рәтен дөрес төзү булса, икенчедән, тулы аңлатмалар һәм мисаллар ярдәмендә исбат итә, укучыга синонимнардан файдалану эшен җиңеләйтә. Мондый төр сүзлекләрдән телне яхшы белүчеләр генә түгел, телне яхшылап белергә омтылучылар, телне яңа өйрәнүчеләр дә файдалана ала.

Икенче төр сүзлекләр — синоним оялар исемлеге. Бу төр сүзлекчәләр синоним турында сүз барган мәкаләләрдә, укучылар һәм югары мәктәп студентлары өчен чыгарылган дәреслек һәм кулланмаларда ук күренә башлый. Татар телендә аерым китап булып чыккан сүзлекләр әлегә күренми. Русларда XVIII нче йөз азагында XIX йөз башында ук инде “синонимы яки сословы” термины белән сүзлекләр төзелә. XX йөздә практик максатны күз алдында тоткан төрле сүзлекләр дөнья күрә; боларның күбесе синонимлык рәтен, чиген билгеләүне максат итеп куймыйча, мәгънәләрен якынча гына булган сүзләрне дә туплап бирә. Мәсәлән, Н.Абрамов (Словарь русских синонимов и сходных по смыслу выражений. — Спб. 1900 г.) *дорога, путь, мостовая, стезя, тропа, тропинка, шоссе; улица, тротуар, просека, аллея, полотно (железнодорожное)* дип, *юл* оясына аның төрләрен, алай гына да түгел, аңа охшаш күренешләрне дә китерә. Ә инде *воин* сүзенә тупланган ояда *воитель, боец, борец, единоборец, ратоборец, поборник, ратник, солдат, рекрут, военный, служилый, вояка, служака, витязь, армеец, гвардеец, артиллерист, гренадер, кавалерист, кирасир, сапер, улан, казак* кебек

сугышчының һәр чорга, һәр төркеменә, дәрәҗәсенә һ.б. караган төрләре дә китерелә. Болар синонимнар сүзлеге булудан да бигрәк, тематик сүзләр исемлегенә якын торалар. Соңгы вакытта чыккан тулырак һәм уңышлырак сүзлек итеп З.Е.Александрованың “Словарь синонимов русского языка” (М. 1975, около 9000 синонимических рядов, изд. IV) хезмәтен китерергә кирәк.

Укучыларга тәкъдим ителә торган безнең сүзлек кайбер яклары (аңлатмасыз, мисалсыз булуы) белән З.Е.Александрова сүзлегенә охшаса да, кайбер төп мәсьәләләрдә ул сүзлектән аерыла. Бу аерымлыкларны санап тормастан, тәкъдим ителә торган “Синонимнар сүзлеге”нең төп принциплары турында язарга булдык.

1. Синонимнар оясында синонимик рәтнең баш сүзе — доминанта була. Бу сүз оядагы барлык сүзләргә караганда да мәгънәне тулырак, конкретрак бирергә һәм телдә иң актив кулланышта булырга тиеш.

2. Доминантадан башка сүзләр синонимнар рәтен тәшкил итәләр. Синонимнар рәте синонимнар оясы терминыннан билгеле бер принципта төзелгән булуы белән аерыла. Ягъни барлык синоним сүзләр бергә оя тәшкил итсәләр дә, ул әле сүзлекнең синонимнар рәте түгел. Синонимнар рәте баш сүздән — доминантадан мәгънә якынлыклары кими бару, ягъни мәгънә төсмерләре белән аерыла бару тәртибендә ерагаялар, ә искергән яки аерым сөйләшләрдә генә йөргән диалекталь сүзләр стилистик максатта әдәби әсәрдә кулланылуын истә тотып, иң соңыннан, синонимнар рәтенең азагына өстәләләр. Синонимнар рәтендәге сүзләр арасындагы аермалар төрле типта булган очракта, мәсәлән, мәгънәне төрле яктан характерлау, сүзне аңлата торган билгеләрнең дәрәҗәсе, табылу күләме төрле булу, кайберләренең аерым берничә сүз янында гына килә алуы һ.б. очракта синонимнар рәтенә урнаштыру сүзләрнең телдә куллану ешлыгына, активлыгына нигезләнә.

Синонимнар рәтендә аерым сүзләр генә түгел, шул ук төшенчәне бирә торган сүзтезмәләр дә урын ала. Ә кайбер ояларда синонимлыкны тамыр сүзләр түгел, ә шул тамырга ялганган кушымчалар бирсә дә, синонимнар рәтенә болар тамырдаш сүзләр буларак урнаштырылалар. Мәсәлән, *мутовка, месилка* мәгънәсендәге *болгаткыч, болгавыч, туглагыч, туглавыч, атлавыч, аталавыч* сүзләреннән торган ояда өч тамырдан ясалган алты сүз бар. Мондый хәлне *эшчән—эшлекле, булган—булдыклы, дини—диндар—динчел* кебек синоним парларда да очратабыз.

Сүзлеккә телнең барлык сүз төркемнәреннән дә синонимнар алынды. Татар телендә синонимнарга иң бай сүз төркеме фигыль һәм сыйфатлар икәнлеге күренде. Фигыль яки сыйфатлардан торган синонимик оялар үзләре күп булу белән генә түгел, һәр оя бик бай — унар һәм аннан да артык берәмлектән торуы ягыннан да күзгә ташлана. Рәвешләр дә синонимнарга бай. Исемнәрдә абстракт сүзләр, хәтта конкрет предмет атамасы булган сүзләрдә дә синонимлык шактый гына.

Синонимлыкның күпмәгънәлелек белән бәйләнешен, мөнәсәбәтен аерым күрсәтеп, басым ясап әйтергә кирәк. Бу сүзлектән дә күренгәнчә, күпмәгънәле сүзләр доминанта буларак еш очрамыйлар. Бер үк сүзне исем һәм сыйфат (*алама, белдерү, ялгыш, пычрак* һ.б.) яки исем һәм фигыль (*атлау, салу* һ.б.), *дуамал* кебек сыйфат һәм рәвеш булып килгән очракларда, *җирлек, олге, җибәрү, өлгерү, төзәтү, тотыну, тырышу* һ.б. кебек күпмәгънәле сүзләр яңа оялар доминантасы булып килгәннәр. Күп кенә сүзләр берничә ояга керәләр. Гомумән, татар телендә күпмәгънәле сүзләр шактый, һәм бу синонимнар сүзлегендә дә чагылыш тапкан. Күпмәгънәлелек доминанта сүзләргә караса, омоним рәвешендә аерым оялар итеп 1., 2., саннары белән бирелде, доминанта булып килмәгәннәре, синонимнар исемлегендә кайсы ояга керүенә карап, үз доминантасына **к.** (*кара*) искәрмәсе белән җибәрелде.

Сүзлектә тагын бер үзенчәлек: баш сүзнең кайсы мәгънәсендә килүе һәм синонимик ояның нәрсә аңлатуын ачыклау өчен, сүзлектәге баш сүздән (доминантадан) соң кыскача гына тәрҗемәсе русча китерелде; русча сүзләрдә синонимик ояны биреп бетерү максат итеп куелмады, шулай да кайчак 4-5 сүзгә кадәр саналды. Бу эш сүзлекне, сүзлектәге ояларны тагы тулыландыру, төгәлрәк, конкретрак итү, синонимик ояның чиген билгеләү максатында эшләнде. Мәсәлән, *баз, нәүрәп, чокыр, идән асты* сүзләре *погреб* мәгънәсендә алынды. Ягъни *баз* сүзе үзенең азык саклау өчен җирне казып ясалган, өсте ачып-ябылу итеп эшләнгән урын мәгънәсендә китерелде; *нәүрәп* сүзе нәкъ *баз* мәгънәсендә, аерым якларда гына актив кулланыштагы сүз, әдәби әсәрләрдә дә шактый күренә. Күпмәгънәле *чокыр* сүзе бер мәгънәсе белән генә *баз* сүзенә синоним: *бәрәңге чокыры, чокырдагы бәрәңгебез өшегән, чокырны ачып, бәрәңгене (кишер, чөгендер һ.б.) чыгару* һ.б.ш. Ләкин *чокыр* сүзе төп мәгънәсе белән үзе бер оя ясар иде: *казылма, баз (үзгәрәк мәгънә)* һ.б., бу инде

гомумән *яма* мәгънәсен бирә. *Идән асты* сүзе дә *баз* мәгънәсендә йөри, үзенең урыны — өй астын казып эшләнгән булуы белән аерыла. Кайбер сөйләшләрдә (мишәрләрдә) *пугәрәб* сүзе *баз* мәгънәсендә кулланыла.

Телдә күпмәгънәле сүзләр күп булганлыктан, синонимнарны билгеләүдә сүзнең кайсы мәгънәсендә алынуын ачыкламасаң, синонимнар сүзлеге түгел, ә берничә синонимик рәтне берләштергән тематик сүзләр җыелмасы гына килеп чыгар иде.

Сүзлеккә, бик аз күләмдә булса да, терминнар да алынды, терминнар яки рус теле аша кергән интернациональ сүзләр халыкта йөргән атама-сүзләр белән бер ояга тупланды. Мондый ояларда баш сүз итеп терминнарны алу кулайрак саналса да, кайбер оялар татарча сүзләр белән башланды. Бу бигрәк тә кош, җәнлек, үсемлек, чәчәк атамаларында һәм сәяси-фәлсәфи сүзләрдә күренә. Мәсәлән, *автор, совет, ландыш (чәчәк), этаж, рубин* кебек сүзләр, татарча вариантлары булуга карамастан, баш сүз итеп алынды, ә *икътисад, икътисадый, зияфәт* һ.б.ш. сүзләр, русчалары да актив кулланышта булса да (*экономика, экономик, банкет* һ.б.ш.), баш сүз итеп алынды. Гомумән, ике-өч сүздән торган русча-татарча яки татарча-гарәпчә сүзләр (телдә кайчандыр йөреп тә, хәзер бик үк актив кулланышта булмаганнары) синонимлыгын алмаска тырыштык. Сүзлек — хәзерге тел сүзлеге. Шулай да телдә актив йөргән, яки киләчәктә кулланышка керү мөмкинлеге булган рус һәм искергән гарәп-фарсыдан кергән сүзләр синонимлыкны баетуда нидер бирә ала икән, сүзлек бирәмлеге буларак синоним ояларга беркетелде. Сүзләрне сүзлеккә алу өчен, аларның теге яки бу авторның әдәби әсәрендә кулланылуы, халык авыз иҗатында йөрүе соңгырак чор татарча-русча, русча-татарча сүзлекләрдә очравы, газета-журналларда файдаланылуы нигез итеп алынды.

Сүзлектә фигыльләр исем фигыль формасында (-у -ү) бирелде. Сүз янында аның кулланылыш үзенчәлегенә караган искәрмәләр курсив белән күрсәтелде (мәсәлән, *сөйл., иск., диал.* һ.б.).

Мондый төр сүзлекнең татарларда беренче булуын исәпкә алып, сүзлектә киткән аерым кимчелекләр өчен авторларны укучылар гафу итәр дип уйлыйбыз һәм киләчәктә сыйфатын яхшырту теләге белән үз фикерләрен язып җибәрүләрен үтенәбез.

Бу китапны басарга әзерләгәндә техник яктан зур ярдәмнәре өчен, Казан дәүләт университетының татар теленә өйрәтү кафедрасы доценты Л.М.Ризвановага һәм кафедра хезмәткәре Т.С.Хөсәеновага олуг рәхмәтебезне белдерәбез.

Авторлар

Кыскартылмалар

Бәйл. — бәйлек
диал. — диалекталь
и. — исем
ирон. — иронияле
иск. — искергән
кер. с. — кереш сүз
кис. — кисәкчә
күч. — күчерелмә
мөнәс. с. — мөнәсәбәтле сүз
рәв. — рәвеш
рәсм. — рәсми
с. — сыйфат
сир. — сирәк
сөйл. — сөйләм
ф. — фигыль
хәб. функц. — хәбәр функциясендә